**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР

2022 елның 29 марты №75

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру вәкаләтләре өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

1) милли һәм җирле социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, муниципаль программаларны (подпрограммаларны) формалаштыру һәм гамәлгә ашыру;

2) муниципаль берәмлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләрен анализлау һәм аны үстерү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү фаразлары буенча чаралар куллану нәтиҗәлелеген анализлау;

3) муниципаль берәмлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын формалаштыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү;

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар һәм әлеге оешмаларның структур бүлекчәләре эшчәнлегенә ярдәм итү;

5) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшмә органнарын төзү.

2. Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетына Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Бишнә авыл җирлеге бюджетыннан Яшел Үзән муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә башкарыла.

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Бишнә авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**